КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 декабрь г.Казань № 1408

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә Сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләр донорының сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрен алу урынына үтү һәм кире кайту өчен түләү чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен һәм Сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләр донорының сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрен алу урынына үтү һәм кире кайту өчен түләү чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү күләме һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләр донорының сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрен алу урынына үтү һәм кире кайту өчен түләү чыгымнарны финанс белән тәэмин итү турында» 2022 елның 19 августындагы 1460 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләр донорының сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрен алу урынына үтү һәм кире кайту өчен түләү чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында федераль бюджеттан

Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибе;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләр донорының сөяк мие һәм (яисә) гемопоэтик кәүсә күзәнәкләрен алу урынына үтү һәм кире кайту өчен түләү чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирү күләме һәм шартларын билгеләү тәртибе.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин